Фәүзия БӘЙРӘМОВА

Ахырзаман АФӘТЕ

Фәүзия БӘЙРӘМОВА



Ахырзаман АФӘТЕ

Публицистика

Чаллы
2002

ББК 74.200.54
Б 86

Бәйрәмова Фәүзия
Б 86 Ахырзаман афәте: Публицистика: Яр Чаллы, "Аяз" нәшрияты, 2002. — 48 бит.

Татар милләте һәм наркомания...

Милләтебез тормышына кара тамырларын җибәреп өлгергән ахырзаман афәте... Аңа каршы көрәшеп буламы, адәм баласын бу куркыныч чирдән ничек саклап калырга, наркомафия нигә һаман тиешле җәзасын алмый?

Автор үзенең бу китабында менә шушы катлаулы сорауларга җавап табарга омтыла, милләтне наркомания афәте хакында кисәтә. Китап киң катлам укучыларга, бигрәк тә ата-аналарга, укытучыларга, яшьләргә адреслана.

Бу китап Чаллы шәһәре СПИДка каршы көрәш һәм профилактика үзәгенең матди ярдәме белән чыгарыла. Сатылмый, бушка таратыла.

ББК 74.200.54.

© Фәүзия Бәйрәмова
© "Аяз" нәшрияты

Ахырзаман афәте

Татар халкы үз тарихында күпне күрде, әмма аның мондый хәлне — эчтән таркалып яту фаҗигасен кичергәне юк иде... Әйе, милләтебез дәүләт югалту бәхетсезлеген дә күрде, илсез, җирсез, телсез калу кайгыларын да белде, динсезлек чорларын да үз башыннан кичерде. Татар бугазыннан алып Кавказ тауларына кадәр ара татарлар белән түшәлде, Россия алып барган бөтен сугышларда сөлектәй татар ирләре кырылды, Себер төрмәләрендә дин, ирек, җир өчен көрәшкән иң көчле татарлар юк ителде... Россия 500 ел буе татар милләтенә каршы игълан ителмәгән сугыш алып барды, әмма татарның орлыгын бетерә алмады. Бер ир үлсә, калган ун баласы тырмашып аякка басты, Казаннан кусалар, Уфага, Ырынбур далаларына барып урнашты, шахтасына төште, урман кисте, сазга батып, нефть чыгарды, Магниткадан башлап, метросына кадәр төзеп бирде, иген үстерде, мал көтте... Татар кешесе, Россиянең бөтен кара эшен сыртына салып, бүгенгә хәтле килеп җитә алды... "Эшләп кеше үлми" дигән әйтем бар, әмма аның дәвамы бик гыйбрәтле — "...кон дә күрми". Гасырларча барган шушы орыш-тормышта татар үлмәс өчен, тән-җан саклау өчен шулай ат кебек эшләгән булып чыкты. Милләтнең рух биеклеге, акыл, аң камиллеге, иман ныклыгы, зыялылык, мәдәнилек юнәлешендә эшләү иң арткы урында калган яки бөтенләй дә булмаган булып чыкты. Без, татарлар, 500 еллык бу төрмә шартларында да исән кала алдык, әмма инде, тоташ ирексезлектә яшәп, рухыбыз гарипләнгән, иманыбыз имгәнгән, холкыбыз бозылган,

үзгәргән, көйсезләнгән булып чыкты... Әйе, без — бар, без — исән, без инде үзебезгә күрә ирекле дә, әмма нинди соң без хәзер, бу яңа заманның яңа сынауларын җиңә алырлыкмы, рух-орлыгыбыз исәнме?

Начар орлыктан зәгыйфь үсенте чыга, аны чүп үләне һәм корт басып китә. Бөтен көчен яшәү өчен, дым һәм туфрак хакына көрәшеп уздырган үсенте, нәтиҗәдә, бөтенләй дә нәселсез калырга мөмкин... Калган очракта да, ул инде тагы да зәгыйфь орлык, корт төшкән җимеш була. Шулай итеп, авыру баскан агачлар әкренләп корый, үлән-үсентеләр үлә, гөл-чәчкәләр сабагында кофтлап ава... Милләт белән дә шулай. Әгәр аның эченә корт төшкән икән, әгәр аның нәсел орлыгы чери башлаган икән, бу милләт әкренләп үзенең бетүенә, юкка чыгуына таба бара... Әгәр милләт, өстенә килгән шушы фаҗигане аңлап, кискен чаралар күрмәсә, чиреннән арынмаса, һаман эчтән черен ятуын дәвам итсә, әлбәттә, аны бетү көтә...

Нинди авыр заманнарда да аягында басып кала алган татар бүген үзәгенә корт төшкән имән агачын хәтерләтә. Читтән карагандa, имән әле шаулый, тамырлары җиде кат җир астына киткән, ботаклары җиде кат күккә җиткән... Әмма бу мәгърур имәннең инде үзәгенә корт төшкән... Корт күче үрчи, миллионлаган корткыч көне-төне имәннең үзәген кимерә, яшәү сутын суыра, бәгырен ашый... Һәм көннәрдән бер көнне бу яшел агач шаулап утырган җиреннән гөрселдәп җиргә авачак... Әгәр агачның үзендә корткыч бөҗәкләргә каршы тору көче калмаса, бу авыруына каршы үзен чорнап алган табигатьтән файдалана алмаса, бу имән агачы черен авачак...

Безнең үзәгебезгә кайчан корт төште соң? Татарның кайчан тәне һәм җаны чери башлады? Нинди авырлыклардан, фаҗигаләрдән дә исән калып, ярты дөньяның йөген үз иңнәренә

салып, бүгенгә хәтле исән-имин килеп җитә алган милләт иде бит ул. Нигә бүген аягүрә үлеп бара ул? Сорауны болай кискен куюу күпләрне тетрәндерер, куркытыр. "Юк, юк, нишләп бетсен ди татар, әнә бит, җырлап-биеп, матур итеп бәйрәмнәр уздырып, гөрләтеп яшәп яталар!" — диярләр... Фаҗиганең бәйрәмчә киенеп-ясанып, аракы белән кочаклашып, азгын хатын кебек уйнаклап, инде һәр татарның ишеген шакыганын, һәр гаиләнең түренә үтеп маташканын күпләр күрмәмешкә салышырга тырышырлар...

Бүген ачыктан-ачык әйтергә була: татар милләтенең фаҗигасе аракы эчүдән башланды. Без эчәргә тиешле милләт түгел идек. Эчүне безгә, мөселман-татарларга, Аллаһы Тәгалә Үзе тыйган иде. Милләт Аллаһны тыңламады. Инде эчеп бетеп барабыз — язучысы эчә, галиме, энгчесе, энесезе, атасы, баласы, анасы — барысы да диярлек эчә... Аерма шунда гына — кем яшереп эчә, кем — ачыктан-ачык... Кем әлегә аз гына эчә, кем инде эчмичә бөтенләй тора алмый... Һәм барысы да, кулга аракы шешәсе тотып, милләтне коткарып калу юлларын эзлиләр... Ә милләтнең инде үзәгенә корт төшкән, бу кешеләрнең үзләренең үзәкләренә, тормышларына корткыч кергән. Шуннан арынмый торып, ничек итеп милләтне коткару турында буш сүзләр сөйләп ятарга мөмкин?!

Аракы аша милләткә зина килде, татар тормышына азгынлык, бозыклык, хыянәт кебек нәрсәләр үтеп керде. Эчкән ир җиңел генә башка хатын белән хыянәт итте, эчкән хатын җиңел генә башка ирне кабул итте... Татар тормышында аталы ятимнәр, атасыз ятимнәр, уйнаштан туганнар, "мать-одиночка"лар, никахсызлар, ирле яки ирсез фәхишәләр — тагы әллә кемнәр, әллә нинди бәндәләр барлыкка килде. Тән һәм җан азгынлыгы мәхәббәт мамыгына төрелде, шундый "мәхәббәт"кә мәдхия укып, әсәрләр язылды, җырлар җырланды, тамашалар куелды... Без кычкырып елыйсы урында

рәхәтләнеп көлдек, акырып җырладык, аракыдан һәм азгынлыктан торган тормышыбызны мәдәниятле итеп күрсәтергә тырыштык. Чөнки инде без бу хәлләргә ияләшкән идек, шуңа күрә татарның мондый бозык тормышына кискен каршы төшмәдек, җырладык та биедек, җырладык та биедек...

Зәгыйфь орлыктан зәгыйфь үсенте чыга...
Күп очракта, исеректән исерек туа...

Татарда бүген өченче буын исерекләр китте — сугыш чорындагы салмыш бабалары, аларның сугыштан соң туган исерек уллары һәм шушы исерек аталардан туган бүгенге буын — исерек-наркоман татар егетләре... Татар тормышында 50—60 ел элек башланган кортлау, черү процессы бүген иң куркыныч чорына — наркомания чорына кереп бара. Шушы вакыт эчендә эчкече татар ирләренең наркоман уллары үсеп җитте... Милләт ишегеннән соңгы афәт, кара куркыныч афәт — наркомания шакый башлады... Аңа ияреп, милли йортыбыз ишегенә СПИД дигән өрәк, СПИД дигән үләт килеп сөялде... Тагы бер мизгел, тагы бер талпыну — һәм ул өрәк татар өенең түренә менеп утырырга мөмкин... Бу ахырзаман афәте һәрберебезнең өенә керергә үз җаен эзли, үз вакытын көтә — исерек ирләр, зиначы хатыннар, наркоман балалар аша... Кайбер табибларның битарафлыгы һәм намуссызлыгы аркасында... Мәкер һәм җинаять юлы белән... СПИД һәрберебезнең кан тамырларына үтеп кереп, тәнебезгә хуҗа булырга һәм үзе белән салкын гүргә алып китәргә омтыла... Әгәр без моңа юл куеп торсак, әгәр без бу афәткә каршы көрәшә белмәсәк һәм көрәшергә теләмәсәк, шулай булачак та.

Бүгенге көндә Татарстанда 2000 нән артык СПИД чире йөртүче бар. Бу — әле исәпкә алынганнары гына. Ә исәптә

тормаучылар, егылып үлүчеләр, юкка чыгучылар күпме? СПИД эпидемиясе көннән-көн котырып җәелә, шушы берничә елда Россиядә миллионнан артык үлем чире йөртүчеләр булуы котелә. Татарстанда, бигрәк тә Чаллы, Казан, Бөгелмә, Әлмәт шәһәрләрендә, бу куркыныч вирусны йөртүчеләр көннән-көн арта бара. Авыл районнарыннан бары тик Актаныш һәм Мөслимдә генә хәзергә СПИД белән авыручылар юк, калганнарының барысына да инде бу үлем үләте үтеп кергән. СПИД, нигездә, яшьләрне, наркоманнарны кыра, алар аша сәламәт кешеләргә, бөтен җәмгыятькә, барыбызга да яный...

Ә без... "Милләт җырлый-бии бит әле", — дибез! Бу җыр-биюләрне, туктаусыз күңел ачуларны туктатып торыйк та, бик җитди итеп уйлыйк, киңәшик әле, җәмәгать! Наркомания — ул эчкечелек кенә түгел, ул үзе килепябышкан кешене тәмам бетермичә туктамый. Татар халкы аракыга җиңел генә ияләнгән кебек, наркоманиягә дә инде күнегеп бара. Кемнеңдер — улы, кемнеңдер — кызы, кияве, киленe наркоман, туганнары, күршеләре "инәдә утыра". Нәселенә бу чир кермәгәннәргә дә наркомания икенче яктан килеп яный — кемнедер наркоманнар талаган, кемнедер үтергәннәр, кемнедер кыйнап гарип калдырганнар... Ә наркоманнар арасында артык доза алудан үлүчеләр күпме?! Наркомания зур-зур җитәкчеләрнең балаларын да, гади хезмәт кешесе баласын да аяп тормый, артык күп наркотиклар кулланып, яшь-яшьтән үлеп китәләр. Боларны халыктан яшерделәр, кайсында — йөрәк, кайсында — кан авыруы диделәр. Күпме артистларның, җырчыларның, рәссамнарның балалары бүген наркоман булып йөриләр! Болары — күзгә күренгәннәре, ә гади халыкның ялгыз башына килгән фаҗигасен, аларның наркоман балаларын, гомумән, исәпкә-санга алучы да юк. Бу хакта чып-чын

сөйлиләр дә тыналар. Югыйсә, сүз ахырзаман афәте булган иң куркыныч чирләрнең берсе — наркомания турында бара! Бу хакта бары тик бик җитди итеп сөйләшергә һәм кискен адымнар ясарга кирәк. Татар халкы әзерме бу сөйләшүгә? Югыйсә, наркоманиягә каршы көрәш модалы тамашаларга, телемарафон белән акча җыюларга, бушлай презерватив һәм шприцлар таратуга гына әйләнеп бара бит! Ә сүз меңнәрнең фаҗигасе, канлы күз яшьләре, өзелергә торган гомерләре турында бара... Татар халкы бу афәткә каршы торырга бөтенләй әзерлексез булып чыкты. Бүгенге көндә аның наркомания турында, аны булдырмый калу чаралары, бу чиргә каршы көрәш юллары хакында мәгълүматы бик аз. Бу язмабыз, бәлки, кайбер мәсьәләләргә ачыклык кертер, дип уйлыйбыз.

Әйе, татар халкы өчен наркомания — чагыштырмача яңа күренеш. Әмма, шул ук вакытта, алкогольнең дә наркотик икәнен искә алсак, милләт бу хәл белән бер гасырга якын таныш, чөнки аерым татарлар арасында XX гасыр башында ук эчкечеләр булган. Тәмәке составында да өлешчә наркотик матдәләр бар, бу зәхмәт белән дә татарлар инде йөз елга якын таныш. Шулай ук теге заманнарда кайбер сәүдәгәрләрнең һәм хәтта дин әһелләренең әфьюн кулланганнары билгеле. Әмма болар — санаулы гына кешеләр, милләт әле бу гасырда да тоташы белән наркоманиянең нәрсә икәнен белмәгән, аны кулланмаган, үзен мингерәйтергә ирек бирмәгән. Наркомания афәтенең, кара дулкын булып, милләтебез тормышына бәреп керүенә нибары 10—15 ел... Шушы вакыт эчендә бу кара өермә меңләгән гаиләләрнең астын-өскә китереп ташлады, җимерде, үтерде, үтертте, киләчәк өчен СПИДның агулы орлыкларын чәчеп калдырды. Рәсми мәгълүматлар буенча, бүгенге көндә Татарстанда 120 мең наркоман исәпләнә. Табиблар әйтүенчә, бу төгәл сан түгел, Татарстанда наркоманнар саны күпкә артык

булырга тиеш. Һәр наркоманның үзе артыннан тагы 6—7 кешене өстерәгәне билгеле, бик күп наркоманнар, бигрәк тә бай, билгеле кешеләрнең балалары, бернинди хисапта да тормыйлар. Шуларның барысын да исәпкә алсаң, Татарстанда наркоманнар саны миллионга якын булырга тиеш. Бу — бик куркыныч сан, республикада 4—5 кешенең берсе — наркоман дигән сүз. Бу — меңләгән ата-ана һәр көн газиз баласын бу афәттән коткару өчен җан тартыша дигән сүз. Бу — наркотиклар өчен сарыф ителгән меңләгән-миллионлаган сум акча, өйдән чыгарып сатылган мал-мөлкәт, наркотиклар өчен башкалардан талап алынган байлык, бер чеметем агу хакына үтерелгән кешеләр һәм наркоманнарның үзләренең дә вакытсыз тауналып өзелгән гомерләре дигән сүз... Чаллы шәһәренең СПИДка каршы көрәш һәм профилактика үзәге баш табибы Галимҗан әфәнде Зариповның әйтүенчә, әгәр наркомания буенча дәүләт кискен чаралар күрмәсә, алдагы 20 ел вакыт эчендә Татарстан халкы ике тапкырга кимергә мөмкин икән. Ягъни наркомания афәте аркасында республика халкының яртысы юкка чыгачак. Уйлап карагыз, игътибар итегез, тетрәнегез, бу — нибары 20 ел вакыт эчендә һәр ике кешенең берсе бетә дигән сүз! Казан шәһәренең яртысы юк, Чаллының, районнарның, авылларның... Татарстанда туучылар саны кискен рәвештә кимегәндә, үлүчеләр саны болай да туучылардан артып киткәндә, аңа инде наркомания корбаннары да килеп кушылу, бу бәла түгелмени?! Бу татар башына килгән фаҗигаләрнең, бәхетсезлекләрнең, кайгының иң зуры түгелмени?! Татар дим, чөнки бу наркоманнарның яртысы — безнең милләт балалары. Чаллы шәһәрендә исәпләнүче 25 мең наркоманның 70 проценты — катнаш никахлардан туган балалар... Никадәр фаҗига, никадәр кыйбласызлык һәм юлсызлык, никадәр ачы күз яшьле гыйбрәт!!! Кем әйтә — ике милләт вәкиле кушылып, даһилар туа дип? Ике милләт вәкиле кушылып, наркоманнар туа икән бит, бүгенге тарих монысын да исбат итте инде.

Зиратларда бүген картларга урын юк, анда яшь-яшь наркоманнарның каберләре... Урыс зиратларында татар балалары, татарныкында — урыслар, катнаш никах корбаннары... Мәхәббәт аларның берсен дә бу бәлаләрдән саклап кала алмаган...

Әйе, татар милләте наркомания афәтенә бөтенләй әзер түгел иде. Ул әле аны бүген дә аңлап бетерми, бу хәлнең никадәр куркыныч икәнен күз алдына китерә алмый, наркомания һәр гаиләгә, һәр кешенең тормышына аерым-аерым, яшеренеп килә, сиздермичә үтеп керә. Шуңа күрә ул сугыш, ачлык, җир тетрәү кебек күренешләрдән дә куркынычрак, чөнки ил өстенә килгән мондый кайгыларны халык ил белән бергә күтәрә. Ә бу афәт — яшерен, куркыныч чир кебек, ул адәм баласының җанын, гомерен аерым-аерым кимерә, аерым-аерым суыра, аерым-аерым юк итә... Татар халкының холкы, менталитеты шундый — ул үз тормышында булган мондый яман хәлләрне кешедән яшерә, сиздермәскә, белдермәскә тырыша, берүзе газаплана, берүзе бәргәләнә. Шәһәр җирләрендә, тимер ишекләр, тимер рәшәткәләр артында, татар гаиләләрендә нинди хәсрәтле хәлләр булып ятканын күз алдына китерсәгез иде сез?! Бердәнбер газиз баласы наркоманга әйләнгән, кан юлына шул агуны җибәрмичә инде яши алмаган, вакытында наркотиклар таба алмаса, бөтен тәнен көзән җыерып, кан косып, үлем көтеп яткан баласына бернинди дә ярдәм итә алмаган ата-ананың хәлен кемнәр аңлый икән? Бер яктан, ул аның шушы газапларыннан үлеп китүеннән курка, аны ничек тә коткарып калырга тырыша, елый, өзгәләнә. Икенче яктан, ул инде аның үлүен тели, чөнки баласы, аңга килгәч, тагы аннан наркотиклар өчен акча таптырачак, кыйнаячак, үтерү белән яначак, үз-үзенә кул салу белән куркытачак. Һәм нәтиҗә күп очракта барыбер үлем белән бетә, я баланың, я ата-ананың

үлеме белән... Күп очракта үлемнән соң гына бу йортта барган фаҗига башкаларга билгеле була... Тагы бер татар кешесе, кара кайгыларына уранып, ялгызы бу якты дөньядан китеп бара...

Күп очракта, тормышларына наркомания афәте килеп кергән һәр гаилә, ата-ана бу бәхетсезлек белән башта бер ялгызлары, өйләрендә качып кына көрәшеп карыйлар. Әмма, җиңә алмагач, наркоманиядән котылу юлларын бөтен дөнья буйлап эзләргә тотыналар. Кемдер, баласын җитәкләп, күрәзәче-багучыларга барып карый, кемдер көчле табиблар, диспансерлар эзли башлый, кемдер исә, наркотиклар белән арасын өздерү өчен, газиз баласын үз куллары белән төрмәгә үк утыртып куя... Сөйләячәк бу кыйссабыз соңгысы турында — наркоман оныгын үз куллары белән төрмәгә утырткан бер татар карчыгы хакында.

Разыя апа белән мин беренче тапкыр Чаллы шәһәренең СПИДка каршы көрәш үзәгендә очраштым. 76 яшьлек җыйнак кына бу татар карчыгы шәһәрнең ГЭС бистәсендә наркоманнарның котын ала торган бер көчкә әверелгән. Газиз оныгын саклап калу өчен башланган көрәш шәһәрдә наркоманиягә, наркотик сатучыларга каршы көрәшкә әйләнеп киткән. Наркотик сатучылар әбине куркытып, янап, хәтта ишеген яндырып та караганнар, ә ул барыбер аларның ояларын туздыра тора. Наркоманнарның артларыннан тагылып барып, наркотик сатучыларны ачыклый, квартира, машина номерларын язып ала, милициягә хәбәр итә. Әгәр милиция аларга кагылмый икән, үзе килеп наркотик сатучыларны туздырып ташлый, бөтен дөньяга фаш итә. Әйтерсең лә, газиз оныгыннан наркоман ясаганнары өчен, ул әнә шулай наркоманнар дөньясыннан үч ала, карт куллары белән бу агулы тамырларны милләт тормышыннан йолкып атарга тели, үзе булдыра алганны эшләп калырга ашыга...

Разыя апа үзе Кемерово якларында туып үсә, ә гомеренең төп өлеше бирedә — Чаллы шәһәрендә үтә. Ул гомер буе кешеләргә ризык пешерә. Ире рус милләтеннән була, ул иртә үлә. Разыя апа бердәнбер кызын ялгызы карап аякка бастыра. Кызы да үсеп җитеп, рус кешесенә кияүгә чыга, аннан өч кыз бала таба. Менә шул кыз балаларның олысы юрист булып китә, икенчесе үз гаиләсен корып, балалар үстерә башлый, ә өченчесе — Разыя апаның иң яраткан оныгы Тәнзилә-Тамарасы — наркоманга әйләнә... Арада иң чибәре, күз явын алырлык сылу кыз бала 18 яшеннән наркоман булып китә. Тәртипле генә, үз кул көче белән эшләп яшәп яткан гаиләне, әйтерсең лә, کояшлы көнне яшен суга! Ата-ана, кыз туганнар югалып калалар, Разыя апа исә, соңгы көчләрен җыеп, яраткан оныгын наркомания тырнагыннан тартып алырга ташлана. Нәрсә генә эшләп карамый ул Тәнзиләсен наркоманиядән коткару өчен! Башта, әлбәттә, җитәкләп, табиб-наркологларга алып барып карый, әмма яшь организм даруга түгел, агуга ыргыла, чөнки Тәнзилә инде героинсыз тора алмас хәлгә килгән була. Өйдән күп әйберләр юкка чыга. Тәнзилә һаман әбисеннән, елап, куркытып, ялварып, соңгы акчаларын таптыра. Кулына акча килеп керүгә, наркотик сатучылар янына йөгерә, ә әби аның артыннан күзәтеп бара. Тәнзилә кайдан барып наркотик ала — әби барысын да язып ала. Аннан наркотик сатучылар турында милициягә хәбәр бирә. Наркотик сатучыларның боларын кулга алалар, әмма наркоман кыз Тәнзилә бик тиз генә башкаларын эзләп таба. Ул инде, наркотиклар эзләп, утлы җәһәннәмнең үзенә төшәргә дә әзер була. Әби аны ике тапкыр наркодиспансерга салып карый — барыбер файдасы булмый, кыз кадавын дәвам итә. Үзе исә күзгә күренеп ябыга, сула башлый, бу хәтле көчле агудан бавыр-бөерләре эшләүдән туктый, әмма кыз калтыранган куллары белән барыбер үзенә наркотиклар кертүен дәвам итә...

Оныгының күзгә карап үлеп баруын күреп, әби тагы бер газаплы адымга барып карый. Бурычка 7 мең сум акча алып торып, оныгын хастаханәгә сала һәм тәнендәге бөтен канын алмаштырттыра! Кан үзгәргәч, кан чистаргач, организмы наркотиклар таләп итмәс, дип уйлый үзенчә. Ләкин, кан үзгәрсә дә, күңел үзгәрми икән шул, хәтер кала, инде азып өлгергән нәфес кала... Һәм Тәнзилә ике айдан соң тагы наркотикларга үрелә, тагы кадый башлый. Кыз ашаудан бөтенләй баш тарта, кадый да — ава, кадый да — ава, көн белән төнне аермас хәлгә килә, яшәү белән үлем арасында чайкалып тора башлый... Әмма шул хәлендә дә әбисе аны ташламый — җылы ванналарга салып, баланың газаплы көзән җыеруларын җиңеләйтергә тырыша, үз сулышын, үз тормышын бирердәй булып, оныгын үлем тырнагыннан алып калырга азаплана. Ә оныгы һаман китә бара, китә бара...

Аягүрә үлеп барган оныгын күреп, Разыя апа соңгы адымын ясый — ул Тәнзиләне төрмәгә утырта. Башта аны өч тәүлек милиция бүлегендә ябып тоталар, аннан, әбинең оештыруы буенча, квартира талауда шаһиттан гаеплегә әйләндереп, Тәнзиләне өч елга Бөгелмә төрмәсенә утыртып та куялар. Әбинең максаты бер генә — оныгын озак срокка һәм көчләп наркотиклардан аеру була.

Тәнзилә бары төрмәдә генә бирегә үзен әбисе утыртканын белә. Ул башта әбисенә бик нык үпкәли, аның белән сөйләшми, китергән әйберләрен алмый. Әмма әби дә төрмә ишеге төбеннән китми, бөтенесе белән танышып, якынаеп өлгерә, бөтенесенең яраткан әбисенә әйләнә. Төрмәдә наркотикларсыз яшәргә өйрәнгәч, Тәнзилә дә әбисенең хаклы булуын аңлый, әбисеннән кичерү сорый, үзе дә аңа булган үпкәсен оныта... Тәнзилә Бөгелмә төрмәсендә ике ел утырып, вакытыннан элек ярлыканып кайта. Хәзер ул наркотиклар кулланмый, эшкә урнашкан, сәламәтлеге дә яхшырган кебек.

Әмма әби моңа карап тынычланмаган, ул оныгын күзәтүне һаман дәвам итә икән.

— Һәр көн кич белән, йоклар алдыннан, яткырып, бөтен тәнен, беләкләрен тикшерәм, — диде Разыя апа миңа бер очрашуыбызда. — Кемнәр белән аралашканнарын, кайда барганнарын гел күзәтеп торам. Хәзергә, Аллага шөкер, ул-бу күренми. Менә иртәгә Коръән укытам, өшкертеп тә карыйм әле... Аны ничек яратканымны белсәгез иде сез?! Мин бит аларны үзем үстердем, алар миңа "әни" дип әйтәләр иде. Төрмәдә дә ул түгел, әйтерсең, мин үзем утырдым! Аны кешегә аңлатып, ышандырып та булмый.

Разыя апаның күзеннән мөлдерәп яшьләре ага. Ул аларны ак яулыгының бер чите белән сөртеп ала, әмма яшьләре һаман тыңламый, әбинең җыерчыклы битләре буйлап, тирән ерганаклар ясап, һаман тәгәриләр дә тәгәриләр...

— Гомер буе ризык арасында эшләп тә, кешенекенә кагылмадым, тормышыма хәрам кертмәдем, — ди ул кайнар яшьләрен туктата алмыйча. — Аллаһы Тәгалә мине картлык көнемдә нигә иң газизем аша җәзаларга уйлады икән? Бу сынаулар, бу газаплар нәрсә өчен икән?

Икебез дә шактый вакыт дәшми утырабыз. Мин бу апаның башка кешеләрнең дә балаларын коткару өчен күпме эш башкарганын беләм. Күп кенә наркоманнар хәзер төрмәләрдән, хастаханәләрдән, ярдәм сорап, шушы татар карчыгына мөрәҗәгать итәләр. Ата-аналарына сөйли алмаганны яшьләр аңа сөйли. Ул кайсына — киңәш белән, кайсыларына эш, уку мәсьәләләрендә конкрет ярдәм итә. Ә кайберләрен... утыртып куюны да кирәк таба.

— Наркотик сатучыларның күбесе наркоманга әйләнә, аларның шактыен утыртырга да туры килде, — ди ул күз яшьләрен сыпырып төшереп, тагы көрәшче усал әбигә әйләнеп. — Соңыннан күбесе рәхмәт әйтте. Наркоманнар алар

бик бәхетсез бәндәләр бит, корбаннар, аларга бу хәлләреннән котылырга ярдәм итәргә кирәк.

Наркомания мәсьәләсе буенча Разыя апаның үз программасы, үз методикасы барлыкка килгән. Ул болар хакында Татарстан Президентына хат язган, Мәскәү телевидениесеннән чыгыш ясаган, матбугатка даими язып тора, СПИД-үзәк, наркодиспансер, хокук саклау органнарыннан кайтып керми, очрашулар уздыра, бу ахырзаман афәте турында туктаусыз яза, сөйли, чаң кага... Менә Разыя апаның төп тәкъдиме:

— Наркоманнарны кичекмәстән җәмгыятьтән аерып алырга, изоляцияләргә кирәк, — ди ул. — Ягъни кимендә бер елга, милиция белән саклана торган аерым биналарга ябып куеп, алар өчен коммуналар оештырырга. Наркоманнарны дару белән дәваларга ярамый, ул дарулар үзләре бик көчле наркотиклар, балаларны аңа ияләндерергә ярамый, алар үзләре көрәшеп, бу хәлләреннән чыгарга өйрәнергә тиешләр. Мин үзем оныгым белән шушы юлны үттем, аннан күп кенә наркоман яшьләргә җылы ванналар, массажлар белән сызлану хәленнән чыгарга ярдәм иттем. Наркоманнар өчен бу ябык биналарда эш урыннары оештырырга кирәк, чөнки хезмәт үзе кешене дәвалый, буш вакытны калдырмый. Әмма барыбер, иң беренче чиратта, наркотик сатучылар белән көрәшергә кирәк, аларны һич кызганмыйча, утыртып бетерергә, иң каты җәзага тартырга кирәк.

Әйе, 76 яшьлек татар карчыгы, чын мәгънәсендә, Чаллы шәһәрендә наркотик сатучыларга каршы ялгыз сугыш ачкан. Ул наркотик сатучыларны, наркобизнес белән шөгыльләнүчеләрне "кеше үтерүчеләр" дип атый, аларны туктату, фаш итү өчен үлем күзенә дә барып керергә әзер тора.

— Элек милиция аларны ала иде, хәзер, нигәдер кагылмыйлар, — ди Разыя апа. — Адресларын бирәм,

шаһитлар алып киләм — алмыйлар. Инде милиция кагылмагач, берничәсен үзем барып туздырдым. Ышанасызмы, минем яшьтәге бер татар карчыгы урамда, көнбагыш саткан булып, астан гына наркотиклар сатып утыра! Мин моны наркоманнар артыннан күзәтеп барып белдем. Алар чебен кебек бит — кайда наркотик саталар, шул тирәдә бөтереләләр. Милициягә әйтеп карадым — тимиләр карчыкка, бу һаман наркотиклар сатып ята. Үзем бардым да көнбагышы-наркотиклары белән бергә тибеп очырдым, үзенә дә эләкте. "Син, оятсыз, карчык башың белән нигә наркотиклар сатып ятасың, нигә балаларны бетерәсең, ничек Алладан курыкмыйсың?!" — дим. Дәшми. Шулай наркотиклар сатып, малаена квартира алып биргән бу, хәзер тагы да зуррагын алырга җыена икән, акча кирәк, ди. Хөкем итүен иттеләр бу карчыкны, әмма, карт инде дип, чыгарып җибәрделәр. Хәзергә күренгәне юк әле, әмма мин аны үлгәнче күзәтәчәкмен.

— Куркыныч түгелме соң, Разыя апа, зыян салулары бар бит? — дим.

— Мин бер Алладан, Аның каршында җавап бирүдән генә куркам, — ди Разыя апа. — Аллаһы Тәгалә барысын да үз урынына куя. Безнең йортта наркотик сатучы бер хатын бар иде. Күпме көрәштем мин аның белән, җиңә алмадым, барыбер сатуын дәвам итте. Аннан белдем, үзе дә наркоманга әйләнеп киткән икән, хәзер наркотикларсыз тора алмаска әйләнгән. Җитмәсә, бер аягы чери башлаган, кулында яшь баласы... "Син үзеңә кешеләрнең каргышы төшкәнне аңладыңмы инде?" — дидем. Бу хәлне башкаларга гыйбрәт булсын өчен сөйлим, Аллаһы Тәгалә барыбер җәзасын бирә мондый кешеләргә... Милиция тотмый дип, куанып йөрмәсеннәр, Аллаһ китереп тотса, борылырга да урыннары булмаячак...

Наркотик сатучылар, наркомафия һәм милициянең элемтәләре турында бүген матбугатта күп язалар. Әлбәттә, хокук саклау органнарын, тулаем, мондый җинаятьчел элемтәдә гаепләргә ярамый, әмма милициядә, суд һәм прокуратура хезмәткәрләре арасында берничә мондый кешенең булуы да — наркоманиягә каршы көрәштә әйтеп бетергесез зыян, әйтеп бетергесез җинаять. Шушы көннәрдә генә Свердловский өлкәсе җитәкчесе Эдуард Россель, телевизордан чыгыш ясап, өлкәдә 650 мең наркоман барлыгы турында, инде 7 яшьлек балаларның да наркоманга әйләнүләре хакында ачынып сөйләде. Ул хокук саклау органнарында эшләүчеләрне, милиция хезмәткәрләрен турыдан-туры наркомафия белән бәйле булуда гаепләде, наркомафия, наркотик таратучылар өчен үлем җәзасы кертүне таләп итте... Казан газеталары да башкала милициясенең наркомафия белән бәйле булулары турында язып, дәлилләр китереп торалар. Бу, әлбәттә, коточкыч хәл. Бүгенге көндә Чаллыда 8 милиция хезмәткәренең СПИД белән чирләве билгеле, ә СПИД — ул, нигездә, наркоманнар авыруы. Без, нигәдер, наркоманнарны укол кадап, егылып ятучылар итеп кенә күз алдына китерәбез. Юк, аларның күбесе безнең арада эшләп һәм укып йөри, алар, хирург булып, операция өстәле янында басып торырга мөмкин, милициядә, төрмәләрдә, хокук саклау органнарында, хәтта следователь-тикшерүче булып эшләүчеләр дә бар, аларны руль артында да күрергә мөмкин, ә җырчыларның күпчелеге, бигрәк тә яшьләр, наркотик кулланмыйча, сәхнәгә дә чыкмый... Инде студентлар, мәктәп укучылары турында әйтеп тә торасы түгел, хәтта укытучылар арасында да наркоманнар барлыгы ачыкланды... Зур-зур җитәкчеләрнең, сәясәтчеләрнең үзләре яки балалары наркоман булуы ачыкланып тора... Армиядә хезмәт итүчеләрнең дә күпчелеге

наркоман булуы билгеле... Гомумән, ил белән, дөнья белән кемнәр идарә итә дигән коточкыч сорау башка килә. 76 яшьлек Разыя апалар гына җиңә алырмы бу ил, милләт өстенә атланып яткан наркомания гыйфритен?..

Чаллы шәһәренең 500 урынында наркотик сату нокталары барлыгы турында миңа шәһәрнең СПИДка каршы көрәш үзәгендә әйткән иделәр. Шәһәрнең һәр йортында, кайбер урыннарда һәр подъездда диярлек шушы агу белән сәүдә итеп ятучылар бар икән.

Нигә аларны тотмыйлар икән соң? дигән сорауга җавап сәеррәк булды. Бу сорауны табиблар үзләре дә хокук саклаучыларга биреп караганнар икән. Аларга:

— Әгәр без бу наркотик сатучыларны кулга алабыз икән, алар урынына тагын 500 урында яшерен сата башлаячаклар. Әле без боларын беләбез, күзәтәбез, эрерәк сәүдәгәрләрнең кулга төшүен көтәбез, боларның ояларын туздырсак, кайда сатканнарын да белмәячәкбез, барысы да яшеренәчәк, — дип җавап биргәннәр.

Бу — бик сәер, шома җавап, мәгънәсез дәлил, әлбәттә. Һәм үзеннән-үзе күңелгә шик килә: тотмыйлар, димәк, тотарга теләмиләр? Наркомания кемнәргәдер ачы хәсрәт, хәерчелек һәм үлем китерсә, кемнәргәдер котырган акчалар, исәпсез-хисапсыз байлык китерә. Бөтен дөньяда наркотиклар тарату буенча кара, канлы базар — наркомафия оешкан. Кемдер ул наркотикларны җитештерә, кемдер илдән илгә күчерә, тарата, кемдер яшереп тота, кемдер сата, кемнәрдер исә боларга "түбә" булып тора... Милләтнең меңләгән балалары — Тәнзиләләр, Эдуардлар, Вероникалар, Радиклар, Русланнар, ата-аналарының соңгы акчаларына наркотик сатып алып, тәннәрен һәм җаннарын агулыйлар... Дөньяда беркатлы Тәнзиләләр булганда, наркотиклар да булачак... Тәнзиләләр ягында балалары өчен утка керергә дә әзер булган ата-аналар,

Разыя апалар булса, наркомафияне күп очракта зур исемле кешеләр саклый. Дистәләгән чикләрне, таможняларны үтеп, Латин Америкасыннан Чаллы шәһәренә хәтле наркотиклар килеп җитә алган икән, димәк, моның артында зур кешеләр тора. Шәһәр урамнарында, подъездларда наркотиклар иркен рәвештә сатылып ята икән, димәк, аларны "дәү абзыйлар" саклый... Бүгенге көндә милләтчеләргә, мөселманнарга карата көрәш бара... **Илгә, милләткә куркыныч милләтче һәм мөселманнар ягыннан түгел, нәкъ менә наркомания, СПИД тарафыннан яный бит!** Нигә ФСБ наркотик сатучыларны тотмый, нигә Россиянең хокук саклау органнары наркобизнеска каршы сугыш игълан итми? Антитеррор дип, ничә еллар буе булмаган террорчыларны аулыйлар, халыкка шуны исбатлау өчен үзләре үк төрле хикмәтләр оештыралар, ә вагон-вагон, самолет-самолет, капчык-капчык наркотиклар ташыган һәм шулар белән бөтен илне агулап яткан наркомафияне күрмиләр?! Россия халкын һаман Чечня белән, мөселманнар белән, булмаган "ваххаби"лар, террористлар белән куркытып торалар, ә ил өстенә килгән чын куркынычны күрмәмешкә салышалар һәм күрсәтмиләр!!! Нигә?! Нигә кулында куәтле армиясе, коралы, көчле хокук саклау органнары, ФСБ, спецназлары булган Россия наркоманияне җиңә алмый? Әллә җиңәргә теләмиме? Берәүләрнең кисәк кенә баеп китүләре, чит илләрдә һәм биредә мәрмәр сарайлар тотулары, депутатлар, эре эшмәкәрләр, зур түрәләр булып китүләре шушы канлы, күз яшьле наркобизнес акчаларына эшләнгәнме әллә? Наркоманиягә каршы көрәш шушы Разыя карчыклар, бәхетсез ата-аналар җилкәсендә генә каламыни инде?

Соңгы вакытта телевидениедән СПИДка, наркоманиягә каршы телемарафоннар, шоу-концертлар күреп, наркоманнарга бушка презерватив һәм шприцлар

таратканнарын белеп, сез: "Әнә бит, дәүләт тә наркоманиягә каршы көрәшә!" — диярсез. Әмма дөрес юлмы соң бу? Наркоманиягә каршы көрәшәбез дигән булып, наркоманияне тагы да ныграк таратуга китермиме бу юл? Бу шоу-концертлардан соң мәйдан тулып шприцлар кала икән, димәк, монда наркоманнарның шайтан туе булган! Алар каршына чыгып баскан җырчылар да, күп очракта, наркоманнар. Кемгә, нигә кирәк бу алдау, бу кылану, көрәшкән булып маташу! Бушка презервативлар, шприцлар таратып йөрү — битлек кигән әхлаксызлык, саташкан, адашкан кешеләр фаҗигасендә изге булып уйнау ул. Бу — айнырга теләгән кеше кулына аракы тоттыру дигән сүз. Айнырга телә, әмма эч! Бу презервативлар һәм шприцлар, имеш, яхшы максат белән таратыла — бу бичараларга СПИД чире йокмасын өчен эшләнә икән бит! Зина кылсаң, кыл, мә, шприцын ук бирәбез — наркоман бул, әмма СПИД йоктырма! Үзең череп үлсәң, үл, әмма башкаларны черетмә... Хәзер мәктәпләрдә дә балаларны "Безопасная форма поведения" дигән булып, "имин зина" серләренә өйрәтүләре билгеле булды. (Чаллы мәктәпләрендә шул исемдәге 600 дәреслек таратылган.) Әгәр дәүләт, җәмгыять зинаны, наркоманияне тыясы урында, аның "имин" юлларын эзли, өйрәтә башлый икән, ягъни шушы зиначылар һәм наркоманнар артыннан китә икән, бу дәүләтне һәм җәмгыятьне ничек дип атарга соң? Зиначылар һәм наркоманнар исеме беләнме? Мөгаен, шулайдыр...

Наркоманиягә этәрүче сәбәпләргә без язмабызның ахырында тукталырбыз, ә хәзер наркоманиягә килү юллары турында бераз язып үтәбез. Наркоманиягә килгән яшьләрнең күпчелеге — кызыксыну корбаннары, башкалар кебек булырга тырышу, кылану нәтиҗәсе. Яшьләр, бигрәк тә балалар, иптәшләреннән калышмаска тырышалар, ахыры ни белән

бетәсен һич уйлап тормастан, башкалар кылганны кылanasылары килә. Бала организмы наркотикларга бик тиз ияләнә, соңыннан ул инде аны ташлый алмый, күп очракта ташларга да теләми. Наркотиклар коллыгыннан бик сирәк кеше генә котыла ала. Наркоманиягә махсус тартып кертелгән яшьләр дә бар. Наркомафия өчен бай клиентларның, акчалы наркоманнарның булуы кирәк. Шуңа күрә алар эшмәкәрләрнең, зур түрәләрнең, исемле, акчалы кешеләрнең балаларын, хатыннарын даими күзәтүдә тоталар, уңайлы мизгел булу белән, аларны төрле юллар белән наркоманиягә тарталар. Менә шундый бай клиентлар — наркомафиянең төп акча чыганагы. Наркоманга наркотиклар һәр көн кирәк, бу бай балалары бик озак еллар мафияне акчага туендырачаклар әле. Ярлы балалары, наркотиклар өчен кеше талап, кеше үтереп акча тапса, байларның ата-аналары, бөтен дөньядан яшерә-яшерә, балаларына үзләре биреп тора. Наркотиклар өчен һәр көн саен 500 сумнан алып 1000 сумга хәтле акча кирәк. Шушы акчаны тапмаса, шушы өлешен кабул итмәсә, наркоман үлем чигенә килеп җитә. Я ул үзе үлә, я, кеше талап, кеше үтереп, шушы акчаны таба. Наркоман, чираттагы доза наркотиклар кирәк булганда, ерткычка әйләнә. Ул хәтта ата-анасын, якыннарын, туганнарын да үтерергә мөмкин. Анда бернинди кызгану хисе дә, ярату, акыл да калмый, ул наркотиклык акча табу өчен барысына да бара... Соңгы вакытта кылынган җинаятьләрнең 70—80 проценты наркоманнар тарафыннан эшләнгән. Һәм шушыларны белә торып, алар кулына бушка шприц тоттыру — ул пычак тоттыру белән бер. Дәүләтнең кубарылып китеп, наркомания тирәсендә ыгы-зыгы килүләре, концерт-тамашалар белән күзгә төтен җибәрүләре — болар барысы да мәсьәләнең никадәр җитди икәнлеген аңлап бетермәүдән. Җырлап-биеп, бушка презерватив таратып кына бу фаҗигадән котылып булмаячак! Бу проблема белән

шөгыльләнүчеләр эшнең төбенә төшеп тормыйлар, милли фаҗигане чираттагы кампаниягә генә әйләндерергә телиләр. Безнең милләткә бу алымнарның берсе дә туры килми, бу кайгы инде концерт-тамашаларны узып бара, безнең милләт балалары презерватив һәм шприцта тәрбияләнмәгән. Димәк, безгә, татар милләтенә, наркомания зәхмәтенә каршы көрәшнең бөтенләй башка юлларын, бөтенләй башка алымнарын табарга туры киләчәк. Милләттә әле бу юлларны эзләү башланмады да, ә зиратларда инде картларга урын юк... Анда яшьләр күчеп бетеп бара...

Наркоманиягә каршы башка илләрдә ничек көрәшәләр соң, аларга бу афәт безгә караганда күпкә иртәрәк килде бит? Монда да ил белән илнең аермасы зур икәнен күрәсең, наркотикларны ирекле сатудан алып, алар өчен үлем җәзасы кулланган илләргә кадәр бар. Әйтик, Европа илләрендә кеше, нигездә, үз иркенә куелган, Голландиядә хәтта кайбер төр наркотиклар ирекле рәвештә сатуга да чыгарылган. Әмма наркоманиядән котылырга теләүчеләр биредә дә тәмуг газаплары үтәләр, чөнки кеше организмы — кайда да кеше организмы инде ул. Россиядән аермалы буларак, Европада инде наркоманиягә каршы көрәшнең, дөресрәге, кешене наркотиклардан арындыруның күп юллары табылган. Биредә күп санлы наркодиспансерлардан алып, төрле клублар, яшерен ярдәм оешмалары, түгәрәкләр, табиб-психологлар эшләп килә. Европа илләрендә наркоман булу әллә ни гаепләнми, шуңа күрә бик яшерелми дә. Әмма, шул ук вакытта, карьера ясау, дәүләт хезмәтендә күтәрелү өчен наркоманлык зур зыян китерергә мөмкин, бигрәк тә сәясәт өлкәсендә. Җитди бизнеста да наркоманнар белән эш йөртмәскә тырышалар. Европа илләрендә дә психикасы нормаль булган кешеләр белән генә эш йөртергә яраталар шул.

Мөселман илләрендә, шулай ук Үзәк Азия илләренең кайберләрендә, Кытайда наркотиклар белән эш итүчеләрне

үлем җәзасы көтә. Бу илләрдә наркотик кертергә тырышучы чит ил кешеләрен дә шундый ук хәл көтә... Биредә инде подъезд саен наркотик сатып торуны күз алдына да китереп булмый...

Россиядә исә 70—80 ел буе наркомания яшерен чир булып торды. Аның хакында кычкырып сөйләмәделәр, язмадылар, әмма шул ук вакытта СССРда наркоманнар да, аларга каршы законнар да, хәтта наркоманнар өчен аерым төрмәләр дә бар иде. Шундый федераль төрмәләрнең берсендә, журналист сыйфатында, минем үземә дә булырга туры килде. Наркомания буенча Россиянең төп төрмәсе, ни өчендер, Әлмәт шәһәрендә булып, озак еллар буе ул татар илендәге елан оясын хәтерләтеп ятты. 1986 елның көзендә, татарлар арасында наркоманнар бармы икән дип кызыксынып, мин шушы төрмәгә килеп чыктым. Мин бирегә бары тик Татарстан юстиция министрлыгы ярдәмендә генә керә алдым, чөнки төрмә халык күзеннән дә, журналистлар күзеннән дә бик нык яшерелгән иде. Шәһәрдән читтә, катлы-катлы тимер чыбык белән уратып алынган төрмәгә атлап керү белән, андагы черек, чалшаеп беткән тере мәетләрне күреп, минем күңелемнән гел бер сорау китмәде — бөтен Россия буенча җыелган бу бозык бәндәләрне нигә безгә китереп тутырганнар? Наркоманнарга ияреп, аларның артыннан наркотиклары да килә бит, моны төрмәдә утыручы егетләр үзләре үк сөйләп торалар. Төрмә белән шәһәр арасында, әйтерсең лә, наркотиклардан күпер салынган, ике арада рәхәтләнеп сату-алу бара... Бәлки татарлар арасында наркотикларның күпләп тарала башлавы нәкъ менә шушы елларда Әлмәт төрмәсеннән башлангандыр да?..

Бу төрмәдә мин татар наркоманнары белән дә очраштым. Алар арасында эшчеләр дә, дарухәнә хезмәткәрләре, шәфкать

тутапллары да, табиб-хирурглар да, музыкантлар, рәссамнар да бар иде. Алар миңа нинди юллар белән наркоманиягә килүләрен сөйләделәр, шулай күп кенә наркоманнарның җинаять эшләре белән дә танышып чыктым. Үзем туплаган мәгълүматлар буенча, мәк, киндер, гашиш, анаша, героин, наркотик тәэсирле көчле дарулар куллануның нинди җинаятьләргә китерүен мисаллар белән дәлилләп, мин зур гына мәкалә яздым. "Ак үлем, кара язмыш" дип аталган бу язмам 1986 елның 30 сентябрендә "Татарстан яшьләре" газетасында басылып та чыкты. Бу татар матбугатында наркоманиягә каршы язылган беренче мәкалә иде. "СССРда наркомания юк" дип йөргән бер заманда наркоманнар төрмәсеннән язылган бу мәкалә татар дөньясында бомба шартлаган кебек булды. Җавап та озак көттермәде — обком органы булган "Социалистик Татарстан" газетасының инде 3 октябрь санында ук, минем язмама каршы "Каш ясыйм дип..." дигән имзасыз реплика басылып чыкты. Анда мине, ягъни журналист Фәүзия Бәйрәмованы, совет яшьләрен наркоман булырга өйрәтүдә гаепләгәннәр иде! Ягъни мин, алар язганча, "каш ясыйм дип, күз чыгарганмын икән бит, нәфрәт уятасы урында, укучыларда наркоманиягә карата кызыксыну гына тудырганмын."

Имзасыз бу репликаның обком һәм органнар тарафыннан әзерләнгәне билгеле иде. Әмма әле эш моның белән генә бетмәде, шушы мәкалә буенча, мин эшләгән "Татарстан яшьләре" газетасы редакторын тиз арада обкомга чакыртып алдылар. Анда аны бик каты "эшкәрткәннәр" һәм бу язмам өчен мине эштән җибәрергә кушканнар. Ул миңа үз теләгем белән эштән китү турында гариза язарга кушты. Мин бу гаризаны язарга мәҗбүр булдым һәм 1986 елның 8 октябрендә, наркоманиягә каршы мәкаләм чыгып, бер атна үтүгә, эшсез урамда калдым...

Боларны ни өчен искә төшерәм? Әгәр без татар тормышында борынлап кына килгән бу гарип күренешкә каршы шул вакытта ук бөтен милләт белән күтәрелгән булсак, бәлки, бүгенге наркоманнарның күбесе булмас та иде. Халыкка бу афәтнең ни дәрәҗәдә куркыныч икәнен аңлату, кисәтү, кирәк икән, куркыту җитмәде. Җәмгыять, милләт үзенең үлекли башлаган чирен яшерергә, юк итеп күрсәтергә тырышты, шул вакытта ук: "Чирлибез бит, җәмәгать, харап булабыз!" — дип әйткән кешеләргә җәза бирелде. Аңа карап, үлекле чир юкка чыкмады, киресенчә, шушы 15 ел вакыт эчендә ул инде үләт чиренә әйләнеп, гаиләләрне, шәһәр һәм авылларны басып китте... Инде моннан соң да, берни булмагандай, күзне йомып кыланыйкмы? "Бу миңа кагылмый", — дип, дөнья кайгысыннан тимер ишекләр артына кереп качыйкмы? Әллә, шушы афәткә каршы кем нәрсә эшли ала, берләшеп көрәшә башлыйкмы? Башка милләтләр, бигрәк тә рус халкы, күптән шулай эшли бит инде.

Наркомания рус милләтенең дә башына төшкән куркыныч бәла булды. Без, татарлар, меңәрләп кырылсак, алар бу афәттән миллионлап юкка чыгып бара. Россиядә бүген наркоманнар саны халыкның 20 процентын тәшкил итә, диләр, бу исә кимендә 15—20 миллион дигән сүз! Бу — үзе бер дәүләт — наркоманнар, СПИДчылар, акылдан шашканнар дәүләте! Рус халкы, бу куркынычны аңлап алып, инде төрле юлларны эзли башлады. Әмма дәүләт, хөкүмәт бу проблемаларга һаман саңгырау әле. Кызганыч, Россиядә дә наркоманиягә каршы көрәш шул концерт-тамашалар һәм бушлай презерватив дәрәҗәсендә генә бара. Исерек килеш булган кебек, наркоманнар белән дә илне алып барырбыз, дип уйлый, ахры, Россия җитәкчеләре! Эчкечелекне хәзер медицина юллары, кодирование аша дәвалап булса,

наркомания һәм СПИД каршында медицина көчсез бит! Дөрес, анда-санда наркомания коллыгыннан котылган кешеләр бар, әмма алар — якыннары ярдәмендә үзләренең психикаларын җиңә алган кешеләр. Хәзерге Россиядә наркоманиядән котылырга дәүләт һәм медицина түгел, аерым кешеләр, ата-аналар, авыруларның туганнары ярдәм итә. Руслар, бигрәк тә бу бәла үзләренә килеп кагылган кешеләр, хәлнең ни дәрәҗәдә куркыныч икәнен тиз аңлыйлар. Өсләренә ишелеп килгән бу бәладән дәүләт тә, тимер ишекләр дә коткарып кала алмасын аңлап, алар үзләре балаларын үлем кочагыннан тартып алырга ташланалар. Мин бер рус хатынының наркоман улын коткару өчен нинди тәмуг газаплары үтүе турында тетрәнеп укыган идем. Танылган артистка, бердәнбер улының наркоман икәнен белгәч, аны карау өчен эшен ташлый, улы өйдәге бөтен әйберләрне сатып бетергәч, улының наркотиксыз үлеп баруын күргәч, өен сата. Бөерләре кибеп саргайган улын шәһәрдән шәһәргә, табибтан табибка йөртеп карый, чиркәүгә, экстрасенсларга бара, файда китерердәй нинди үлән, нинди алым бар — барысын да файдаланып карый. Әмма малай һаман наркотикларын ташлый алмый. Ул арада баланың череп беткән бөерен кисеп ташлыйлар, аның аяклары йөрмәс хәлгә килә. Әллә инде каршына килеп баскан әҗәле куркыта, әллә ананың догалы күз яшьләре коткара, үлем чигенә килеп җиткән малай наркотикларын ташлый! Ана белән бала наркоманияне җиңәләр! Әмма нинди тәмуг газаплары аша үтәргә туры килә аларга!

Менә шундый аналар, наркоманиядән котылган балалар, бергә җыелып, Россия буенча төрле клублар, түгәрәкләр оештырып эшли башладылар. Алар үз башларыннан үткән коточкыч фаҗигадән — наркомания фаҗигасеннән башкаларны саклап калырга тырышалар, тәҗрибә

уртаклашалар, юлларын күрсәтәләр, ярдәм итәләр. Мондый клубларның бигрәк тә Екатеринбург шәһәрендә яхшы эшләп килгәнлеге билгеле. Бирәдә "Благотворительный фонд им. Г.А.Шичко" дип аталган оешма бар. Элек бу фондның төп юнәлеше эчкечелеккә каршы көрәш булса, хәзер ул төп көчен наркоманиягә каршы юнәлдергән. Бу оешманың эчкечеләр һәм наркоманнар белән эшли торган үз методик алымнары, үз программалары, үз табиблары, үзләре бастырып тарата торган күп санлы брошюра-китаплары бар. Иң мөһиме — Шичко алымы белән наркоманиядән терелгән кешеләр бар! Оешманың наркоманиягә каршы көрәштә инде шактый зур һәм кызыклы тәҗрибәсе дә барлыгын әйтеп үтәргә кирәк. Бу фонд наркоманиягә каршы 30 лап китапчык чыгарган. "Судьба наркомана", "Программа по избавлению от наркомании", "Программа для родителей наркоманов", "Псы" наркобизнеса" кебек китаплар белән миңа да танышырга туры килде. Безнең милләттә дә наркоманнар бар, әмма наркоманиягә каршы мондый китаплар юк. Бу китапларда элекке наркоманнарның җан тетрәндергеч хатирәләре, көндәлек язмалары, табиб-психологларның киңәшләре, дини, әдәби әсәрләрдән өзекләр, догалар урнаштырылган. Психолог Шичко методы белән эшләү 12 баскычлы алым дип атала. Аның нигезендә, 50 көндәлек язып, бөтен наркоманлык гомереңне сөйләп бирү, тәүбә алымы тора. Бу — кешене фикерләргә, анализ ясарга, үз тормышыңа, кылганнарыңа бәя бирергә өйрәтә торган психологик алым, универсаль методика. Бер караганда, җиңел юл кебек — бөтен тормышыңны көндәлеккә яздың да котылдың. Әмма көндәлектә сораулар шундый итеп куелган ки, син бөтен күңел каралыгыңны, рәнҗеткән кешеләрне, бөтен чир-зәхмәтләреңне, иң авыр чакларыңны, бөтен югалтуларыңны — барысын да яңадан күреп кичерергә, аек

баштан шул пычрак эчендә яңадан яшәп карарга тиеш буласың. Миңа шушы юл белән наркоманлыктан котыла алган берничә рус егете белән үзебезнең Чаллы шәһәрендә очрашып сөйләшергә туры килде. "Язган көндәлегемне укып чыккач, үземә үк куркыныч булып китте, — диде Володя исемлесе. — Наркоман вакытта бөтен нәрсәгә кул селтәнгән, бер генә теләк — наркотиклар табып кадау теләге генә калган була. Хәтердә казынып, шуның көнен-көнгә кәгазьгә төшерә башлагач, күпме кешеләрне рәнҗеткәнең, күпме алдавың, күпме түбәнлекләргә төшүең күренә. Үз-үзеңнән җирәнә, ояла башлыйсың. Үз тормышымны көндәлек-китап итеп язу минем күзләремне ачты, мин күптән инде наркотиклар кадамыйм, балам наркоман була күрмәсен, мин кичергәннәрне кичермәсен, дип куркам. Мәктәпләрдә очрашулар алып барам, балаларга наркоманиянең ни дәрәҗәдә куркыныч икәнен сөйлим..."

Володя һәм Шичко методы белән аякка баскан башка яшьләр, Чаллы шәһәрендә җыелып, "Оптималист" дип аталган клуб төзегәннәр. Ул Яңа шәһәрнең 1/05 йортында, наркодиспансерның 4,5 этажында урнашкан булып чыкты. Яшьләр, элекке наркоманнар белән очрашып сөйләшү өчен, мин бирегә дә килеп чыктым. Мин килгәндә, клуб әгъзаларының кайсы китап укып, кайберләре чәй эчеп, күңелле генә гәпләшеп утыралар иде. Биредә шимбә — якшәмбедән кала һәр көн, кичке 4 тән 6 га кадәр яшьләр, аларның ата-аналары җыела икән. Клубта наркоманиягә каршы бик күп мәгълүмат, китаплар, газеталар, видеокассеталар тупланган. Биредә тәҗрибәле табиб-психологлар эшли, наркоманнар үзләре дә, ата-аналары да алардан төпле киңәшләр ала алалар. Мин биредә немец, грузин, рус, яһүд милләтеннән булган элекке наркоманнарны күрдем, әмма татарлар очрамады. Хәер, биредә татарлар

күренмәүнең бер сәбәбен мин үзем дә әйтә алам. Шичконың уникаль алымы авыру наркоманнарны дингә, милләткә аермый кебек тоелса да (алар моны үзләре дә кат-кат ассызыклыйлар), бу программа күбрәк христиан динендәге кешеләр өчен эшләнгән дигән тәэсир калды. Әйткәнемчә, табиб киңәшләре белән бергә, христиан дине догалары, христиан дине изгеләренә мөрәҗәгатьләр, аларның тормышларыннан хикәятләр, туктаусыз хач (тәре) символы белән кайнашулар, әлбәттә, татар балалары өчен түгел инде. Болар христианнар өчен, бәлки, ярыйдыр да, әмма безнең милләт күңеленә тәре белән кереп булмый шул. Башта мин бу китапларны, тетрәндергеч язмышлары өчен, гыйбрәт өчен, әллә татарчага да тәрҗемә итимме икән дип уйлаган идем, аннан кире кайттым. Юк, безнең балаларга башка төрлерәк сүз, башка төрлерәк аңлату-вәгазь кирәк. Менә шушы вәгазьне бергәләп тудырырга, башкалардан эшләү методикасын алсак та (көндәлекләр алымы), аңа үз эчтәлегебезне, үз сүзебезне салырга тиешбез.

Бүгенге җәмгыятьтә наркоманнарга карата фикер кискен рәвештә икегә бүленде. Берәүләр наркоманнарны җинаятьчеләр дип атыйлар һәм кичекмәстән барысын да юк итәргә чакыралар. Икенчеләр исә наркоманнарга авырулар итеп карыйлар һәм аларны дәваларга чакыралар. Шушы көннәрдә Мәскәү телевидениесенең "Процесс" тапшыруы күрсәткәнчә, наркоманнарны юк итәргә чакыручылар "дәвалыйк" дигәнгә караганда 3 тапкыр күбрәк булып чыккан! Әйе, наркоманнарның бик сирәкләре генә наркотикларны ташлый ала, йөздән туксан — туксан бише барыбер потенциаль җинаятьче булып кала. Җәмәгатьчелек таләп иткәнчә, наркоманнарны юк итә башласаң, бүгенге көндә Россия халкының биштән берен, нигездә, яшьләрне, кырып

салырга кирәк дигән сүз. Ә наркоманнар, үч алу йөзеннән, шуның хәтле үк сәламәт халыкны юк итәргә алынсалар? Аларның күпчелеге үзләрендә үлем вирусы — СПИД йөртә бит, шунысын да онытырга ярамый! Әгәр җәмгыять наркоманнарга һәм наркоман түгелләргә бүленеп сугыша башлый икән, безгә инде бернинди атом бомбасы кирәкми. Закон нигезендә, ата — баласын, бала — атасын, туган — туганын үтерергә рөхсәт бирергә тиеш булачак. Кайсы ана моңа бара ала, наркоман булса да, ул аның йөрәк парәсе бит! Инде боларын юк иткәннән соң, яңа наркоманнар килеп чыкмас дип, кем әйтә ала? Дөрес, наркоманнарны вакытлыча җәмгыятьтән аерып торырга кирәктер. Әйтик, Екатеринбург шәһәрендә аларны тимер чыбыклар белән батареяларга бәйләп куеп, 2—3 атна буе коры ипидә һәм суда тотып "дәвалыйлар" икән. Шул ук шәһәрдә наркотиклар сатып ятучы барлык чегән таборларын да туздырып ташлаганнар. Әлбәттә, бу да дөрес юл түгелдер, әмма бу чарасызлыктан, 7 яшьлек балаларга хәтле наркоман булганга башкарылган эш. **Наркоманлыкны ташлату өчен, иң беренче, наркотикларга юлны ябарга кирәк. Әгәр наркобизнеска каршы көрәш дәүләт дәрәҗәсендә башланмый икән, бу дәүләтнең, бу милләтнең, бу җәмгыятьнең киләчәге юк.**

Наркоманиягә каршы көрәш өч юнәлештә барырга тиеш, дип уйлыйбыз. **Беренче — наркобизнеска каршы көрәш.** Бу дәүләт күләмендә иң мөһим эш булып, моңа Президент, хөкүмәт, парламент, ФСБ, хокук саклау органнары кушылырга тиеш. Наркомафиягә каршы кичекмәстән закон кабул итеп, наркотик таратучыларга карата үлем җәзасы куллануны кертергә кирәктер? Ләкин монда да бик сак булырга кирәк, Россия бит бу, биредә бер гаепсез кешеләрне дә, үч алу максатыннан, кесәләренә, машиналарына, йортларына наркотиклар ташлап, наркомафия дип, юк итәргә мөмкиннәр...

Икенче юнәлеш — наркоманнар белән эшләү, наркотикларны ташлаттыру өчен көрәш. Әлбәттә, монысы да бик авыр булачак, чөнки төпсез сазлык суырып, йотып барган кешене, ярдәм итмичә генә, бу баткаклыктан коткарып булмаячак. Наркоманнар белән эшләү — ул психологик фактор, монда, көч куллануга караганда, акыл белән, җан, күңелләр аша эш алып барырга кирәктер. Әлбәттә, бу юнәлештә бөтен дөньяда булган уңай үрнәкләрне да файдаланып карарга мөмкин.

Өченче юнәлеш, бәлки, иң мөһимедер — әле наркоманлыкны башламаган яшьләр, балалар белән эшләү. Бигрәк тә, аларның ата-аналары белән эшләү. Наркомания — ул инде нәтиҗә. Шушы аянычлы нәтиҗәгә китерүче сәбәпләрне ачыкламый һәм юк итми торып, без наркоманияне дә җиңә алмаячакбыз. Һәм эшне барыбер гаиләдән, ата-аналардан башларга кирәктер, дип уйлыйм. Баланы ашату, киендерү генә җитми әле, иң беренче, үзең балаңа асклык, гаделлек үрнәге күрсәтә белергә кирәк. Баланың күңеленә юл таба белергә, аны урамның, начар дусларның яман тәэсиреннән саклый белергә, бәла килә икән, балаң өчен көрәшә белергә өйрәнергә кирәк. Аның итәктәге сабыен бу дөньяда ниләр көтеп тора — ата-ана моны яхшы белергә тиеш. КамАЗ төзелешенә авыллардан килеп урнашкан беркатлы кешеләр, сәрхүшкә әйләнеп барган татарлар бу дөньядагы мәкерлек һәм явызлыкны аңлап та бетермиләр, ахры. Нәтиҗәдә, шушындый татарларның балалары наркоманиянең беренче корбаннары булып китәләр дә инде... Наркомания мәсьәләсендә бүгенге ата-аналар балаларына караганда да надан, баласының наркоман икәнен, гадәттә, алар иң соң белүче кешеләр була. Туктаусыз сериаллар каршында утыруларны, җыр-бию, тамашаларны, җыелып күңел ачуларны, һаман корсак, ашау-эчү турында

гына кайгыртуны куеп торырга кирәктер. Кешегә бит әле, корсактан кала, фикерләү өчен баш та бирелгән, балалар хакына булса да, эшләтергә өйрәник миләребезне! Күрәсез бит, безнең өчен беркем уйламый, беркем эшләми, үзебез хәрәкәтләнмәсәк, безне беркем килеп коткармаячак... Оешмаган дәүләттән, үзе дә нәрсә эшләргә кирәген белмәгән мәктәптән көтеп ятарга кирәкми, бала — үзебезнеке бит, хәсрәте дә үзебезгә булачак, дәүләткә, мәктәпкә түгел. Шуңа күрә, ата-аналар балаларына карата даими игътибарда булсыннар иде, бала тормышын мәктәпкә һәм урамга бүлмичә, бербөтен язмыш итеп карарга өйрәнсеннәр иде. Ата-аналар һәр көн белеп һәм күзәтеп торырга тиешле нәрсәләр бар. Әйтик, соңгы вакытта балагыз дәресләрен калдырмыйммы, сугышып, урлашып тотыла башламаганмы, өйдән әйберләр юкка чыга башламадымы, балагыз сездән бик еш акча сорап теңкәгезгә тимиме яки кесәсеннән кинәттән зур суммалы акчалар табылмадымы, бик еш кәефе үзгәрмиме, ялганлый башламадымы, өс-башына игътибарсызланмадымы, тәнендә укол эзләре, күгәргән урыннар барлыкка килмәдеме, йөзе шешенеп, агарып, күз алмалары кызарып, теле каралып китмәдеме, өйдә шприц, энә, ацетон, марганцовка кебек нәрсәләр күренә башламадымы, балагыз йокысызлыктан интекмиме, өйдә кунмаска тырышмыймы — боларның барысын да ата-ана белеп торырга тиеш. Инде бала тормышында шушы хәлләр күзәтелә икән, балагызны коткарырга ашыгыгыз! Ул инде тайгак юлга аяк басып килә... **Беркайчан да онытмагыз — сезнең балагызның наркоман булып китүен теләгән кешеләр бар, алар — наркотик сатучылар, балагызның наркоман дуслары, хәтта үзегезнең шәхси дошманнарыгыз да булуы мөмкин. Онытмагыз — без вәхшиләр илендә, вәхши кешеләр арасында яшибез, бу җыр-биюләр дөньясы артында канлы вакыйгалар булып ята, балаларыгызны саклый күрегез!**

Наркомания — нәтиҗә, дидек. Адәм баласы нинди сәбәпләр аркасында бу тайгак юлга аяк баса соң? Безнең уебызча, эчкечелекнең һәм наркоманиянең төп сәбәбе — ул чынбарлыктан качарга, китәргә тырышу. Дөнья, шул исәптән татар тормышы да, бик гаделсезләнеп, рәхимсезләнеп бара. Бүгенге көндә адәм баласы мең төрле мәсьәлә каршында, хәл итә алмыйча, бер ялгызы басып калды. Торырга почмагың булмау, эшсезлек яки даими артык авыр эш, акчасызлык, укырга керә алмау, кадерсезлек һәм кирәксезлек, саусызлык һәм сансызлык — болар барысы да адәм баласының җанын газаплый торган нәрсәләр. Кеше күңеле бик нечкә бит ул, кеше күңкә түзеп тә, бер авыр сүздән муенына элмәк салырга мөмкин. Эчкечелек һәм наркоманиянең башлануы да нindидер гаделсезлеккә эчке протест, ризалашмау, дөньядан ала алмаган үчне үз-үзеңнән алу, бу гаделсезлек, хаксызлыкны җиңә алмагач, аннан качарга, китәргә тырышу булырга мөмкин. "Мәктәптә укып йөргән үсмер баланың тормышында нинди гаделсезлек булырга мөмкин?" — диярсез. Шуны онытмыйк — балалар бит дөньяны бөтенләй башкача кабул итә. Алар дөньядагы гаделсезлекне безгә караганда да тизрәк сизәргә, күрергә мөмкиннәр. Олылар инде ялганга, фальшка, ясалмалыкка, берне сөйләп, икенчене эшләргә өйрәнгән. Бала өчен болар — ят нәрсә, чирканыч нәрсә. Гаиләдә, ата-анасы арасында барган киеренкелекне, ызгыш, хыянәтне, аерылышуларны бала бик авыр кичерә, ул бу хәлләрне үзгәртә алмый, үзе дә сизмәстән, шушылар өчен ата-анасыннан үч алу юлына баса... Наркотикларга үреләә...

Телевидениедән көн-төн үтереш, хаксызлык, ялган, өендә бары тик ашау-эчү турында гына сүз, мәктәптә ялган, тормышта ялган, ясалмалык, иптәшләре арасында тупаслык, аңламау, кимсетүләр... Бала күрә — аның тормышта таянырлык кешеләре юк, аның бу гаделсезлекләрне җиңәрлек

көче юк. Ата-анасы үзләре хокуксыз, кайсының эше юк, кайсы эшләп тә еллар буе хезмәт хакы ала алмый. Бала бөтенесен дә күрә, сизә... Ул инде бүгенге тормышыннан, алдагы көненнән курка, аны да шушындый гаделсезлек көтеп торганын белә. Һәм, вакытлыча булса да, үзенә шушы ясалма тормышны, наркотиклар алып килгән рәхәт тормышны төзи... Башта, чыннан да, наркотиклар тәэсирендә аңа дөнья матур булып күренә, әйтерсең, бер проблема юк... Әмма бу ясалма тормыш, ясалма рәхәтлек тиз бетә, аны барлыкка китерү өчен, тагы да көчлерәк наркотиклар кирәк була башлый. Организм, күп очракта, бу хәлләргә, бу көчләүләргә түзә алмый — үлү белән җавап бирә. Кеше үлмәсә дә, тора-бара аңа инде наркотиклар бернинди рәхәтлек китерми, тәэсир итми башлый; ул аларны бары тик коточкыч авыртуларын, сызлануларын бастыру өчен генә кулланырга мәҗбүр була.

Күрәсез, кеше чынбарлыктан барыбер кача алмый икән... Бу кырыс чынбарлык аны тормышының һәр почмагыннан сагалап, көтеп тора. Чынбарлыктан ясалма рәвештә качарга түгел, аны таный һәм күрә белергә, көрәшергә һәм җиңәргә өйрәнергә кирәк. Аның өчен кеше үз асылына кайтырга тиеш була. Кеше бу дөньяда үзенең нәрсә өчен яшәгәнен, үзенең җаваплылыгын һәм бурычларын яхшы белергә тиеш. Кешенең иң зур җаваплылыгы — үзен дөньяга барлыкка китергән Аллаһ каршындагы җаваплылык. Тәненең һәр күзәнәге, әйтелгән һәр сүзе, кылган һәр гамәле өчен ул әле Аллаһ каршында басып җавап бирәчәк. Аллаһка чын күңелдән ышанган, Аңа рәхмәтле булган, Аның каргышыннан курыккан, Аллаһ әйткәнчә яшәгән кешегә аракы да, наркотиклар да кирәк түгел. Кешенең ата-анасына һәм туганнарына, үзе кебек үк кешеләргә, әйләнә-тирә мохиткә, үз-үзенә карата да бурычлары һәм җаваплылыгы булырга тиеш. Дөнья каршында шундый зур җаваплылык тойган кеше ясалма тормыш, ясалма рәхәтлекләр эзләми,

тереләй тилереп йөрми, санап кына бирелгән гомерен, көннәрен мәгънә белән, изге гамәлләр белән уздырырга тырыша. Без кайчан балаларыбызны менә шушы юнәлештә тәрбияли башлыйбыз, кайчан менә шундый кешеләр, шундый җәмгыять әзерлибез, шул чагында тормышыбызда эчкечелек тә, наркомания дә, хәрам, гаделсезлекләр дә булмаячак. Безнең тормышыбыз, газиз гомерләребез — Аллаһның әманәте, һәм без аны мәгънәле итеп, рухи саулыкта уздырырга тиешбез. ...Без, татарлар, менә шундый чынбарлык, менә шундый хакыйкый тормыш, гаделлеккә омтылырга тиешбез...

Инде тагы як-ягыбызга карыйк — бүген безнең тормышыбыз нинди соң? Авылларда тоташ эчкечелек, зина, караклык... Шәһәрләрдә дә шул ук хәл — аракы һәм тамаша, зина һәм СПИД, наркомания һәм үтерешләр... Сәрхүш милләт бүген үзе кебек үк исерекләрне, гаделсез, затсыз бәндәләрне түрә итеп түргә утырта, аларга табына, алардан көтә... Гыйбадәтне җыр-бию алыштырды... Милләт азгыннарны алкышлый, бозыклар артыннан бара... СПИДтан үлгән гомосексуалист Рудольф Нуриев истәлегенә Казанда һәр елны халыкара фестиваль уздырыла, милләт бозыклыкны мәңгеләштерә... 70 яшьлек җырчылар сәхнәдән үзләренең женси азгынлыклары турында сөйлиләр — милләт мыңгерәеп кул чаба... Гомосексуалист, исерек җырчылар милләтнең "иманы"на, җанына әйләнә... Татар тормышында барысы да асты-өскә килгән... Яман яхшы булып кабул ителә, яхшы яман итеп күрсәтелә... Нинди авырлыклардан да исән калып, инде бүгенге көнгә килеп җиткән татар милләте, шулай ук, үз азгынлыгыннан черен юкка чыгар микәнни? Татарның баш очында күтәрелгән СПИД хәнҗәре, наркомания балтасы шушы буш, мәгънәсез тормышка үлем җавабы түгелме соң?! Бу фаҗига сезнең иңегезне шакымадымы әле? Наркомания әҗәленең корты сезнең нәсел агачыгызга төшмәдеме? Тимер

ишекләр бу афәттән коткарырмы? Ишекләргә түгел, күңелләргә бозыклыктан тимер калкан кирәк тә, әмма милләт моны аңлыймы соң әле, шуңа каршы көрәшәме, әллә инде үзе дә күптән аракы һәм алдау-азгынлык диңгезендә йөзәме? Шулай икән, Аллаһ безне коткармаячак. Юк дибез икән, без моны аек, гадел тормышыбыз, бер-беребезгә карата рәхим-шәфкатьле булуыбыз, дөрес, хак яшәвебез белән исбатларга тиешбез. ***Татар милләте болай бетәргә тиеш түгел! Шулкадәр зур, тарихлы, мәдәниятле, иманлы, эшчән, матур милләт болай бетәргә тиеш түгел! Ишетәсезме, җәмәгать, болай бетәргә тиеш түгел бит...*** Әйдәгез, бер-беребез кайгысына битараф булмыйк, бер-бербезне туганнарча кызгана, ярата белик һәм ярдәм итик, үзебез дә гадел яшик, башкаларны да шуңа өндик, балаларыбызны ислам дине тәртибендә тәрбиялик, аларга милләтебездә булган иң асыл сыйфатларны гына васыять итеп калдырыйк! Бер-беребезне саклыйк, күңелләребезгә, тормышыбызга, милләтебезгә корткычлар төшәргә ирек бирмик, уяу булыйк...

"Кешеләрнең кылган фәхеш, хәрәм эшләре сәбәпле, җир өсте вә диңгезләр өсте бозылды, Аллаһудан җәза йөзеннән каты ачлык, йогышлы каты чирләр барлыкка килде — кылган бозык эшләренең бәгъзе гөнаһларына дөньяда ук газапны татытмаклыгыбыз өчен, шәт, бозыклыктан яхшылыкка кайтырлар, иман китереп һәм тәүбә итеп, төзәлеп мөселман булырлар".

(КОРЪӘН. "РУМ" сүрәсе, 41 нче аять.)

(Язма "Мәйдан" журналының 2001 ел, август саныннан күчереп бастырыла)

Наркомания - афәт ул

"...Бүген ачыктан-ачык әйтергә була: татар милләтенең фаҗигасе аракы эчүдән башланды. Без эчәргә тиешле милләт түгел идек."

"...Татар тормышында 50—60 ел элек башланган кортлау, черү процессы бүген иң куркыныч чорына — наркомания чорына кереп бара. Шушы вакыт эчендә эчкече татар ирләренең наркоман уллары үсеп җитте. Милләт ишеген соңгы афәт, кара куркыныч афәт — наркомания шакый башлады... Аңа ияреп, милли йортыбыз ишегенә СПИД дигән орәк, СПИД дигән үләт килеп сөялде..."

Ф.Бәйрәмова, "Афәт", ("Мәйдан", август, 2001).

Соңгы вакытта дәүләткүләм куркыныч төс алган наркомания проблемасына эчендә җаны булган беркем дә битараф кала алмый торгандыр. Чаллыда нәшер ителгән яңа әдәби-нәфис, иҗтимагый басма — "Мәйдан" журналының беренче санында ук шәһәребездә яшәп иҗат итүче прозаик, драматург, публицист, шагыйрә, СССР Язучылар берлеге әгъзасы, "Иттифак" партиясе рәисе, Гаяз Исхакый исемендәге бүләк иясе ФӘҮЗИЯ ханым БӘЙРӘМОВАНЫҢ да "Афәт" дип исемләнгән бик тә борчулы һәм саллы публицистик мәкаләсе дөнья күрде. Моңарчы күбрәк ислам дине темасына язган, бер карагандa бу темадан читтә торган кебек тоелган хатын-кыз язучыны наркомания темасына алынырга нәрсә мәҗбүр иткән? Гомумән, язучының бу мәсьәләгә шәхси карашы ничек? Шушы сорауларга җавап эзләп, газетабыз хәбәрчесе Фәүзия

ханым янында булды һәм аның белән әңгәмә үткәрде. Без аны укучылар игътибарына тәкъдим итеп, башкаларны да ачыктан-ачык сөйләшүгә, үз фикерләрен һәм тәкъдимнәрен белдерергә чакырабыз.

— Дөрестән дә, соңгы вакытта мин аралаша торган мохитта —дин әһелләре, мөселманнар арасында наркомания проблемасы, бу ахырзаман чире юк, Әлхәмдүлилләһ! Әмма бу бәла, кайгы-хәсрәт милләт тормышында бар... Күзгә күренмәгән наркомания афәте, яҗүҗмәүҗиҗ чирүе кебек, милләтне эчтән кимерең, ашап, юк итеп килә. Мондый чакта: "Бу проблема миңа кагылмый", — диц, кеше кайгысына читтән генә карап тору — гөнаһ булыр иде. Аллаһы Тәгалә теге дөньяга баргач, сораячак бит: "Халкың шундый хәлләргә төшкәндә, син аңа ярдәм итү өчен нәрсә эшләдең?" — диячәк. Аллаһтан курку, милләтемне кызгану мине, язучы буларак шушы темага тотынырга, аны өйрәнергә һәм бу хакта зур итеп язарга этәрде. Мин, язучы кеше, халыкка наркомания афәте турында йөрәгенә үтәрлек итеп аңлатырга тиеш идем. Аллага шөкер, мин бу эшне башкарып чыга алдым.

— Мәкаләне язганда Сезгә наркоманиягә каршы көрәшүче җәмәгать оешмаларында да булырга туры килгән. Сез аларның ролен ничек бәялисез? Бу оешмаларга күбрәк инде наркомания афәте ишекләрен шакып өлгергән, бераз соңга калган кешеләр генә килә кебек... Татарлар өчен, бәлки, аерым оешмалар төзү кирәктер?

— Әйе, хезмәтемне язар алдыннан, наркоманиягә, СПИДка каршы көрәшә торган күп кенә оешмаларда, клубларда булдым, аерым кешеләр белән махсус очрашулар үткәрдем, бик күп фәнни, популяр язмалар белән танышып чыктым. Әлбәттә, мондый оешмаларның, бу язмаларның әһәмияте бәяләп бетергесез, наркоманиягә, СПИДка каршы, гадәт-

тә, хәзергә алар гына көрәшә, алар гына чаң кага. Дәүләтнең бу проблема өстендә эшләве хәзергә "одноразовый шприц" хәлен хәтерләтә, ягъни, дәүләт наркомания афәте турында хәзергә очрактан-очракка гына эшләп ала. Әгәр наркомания, СПИД чиренә карата дәүләт киң колачлы программа эшләп, бу афәткә каршы киң фронт белән хәрәкәт итә башламый икән, Россия, Татарстан бик тиздән тоташы белән наркоманнар, ВИЧ инфекциялеләр һәм җинаятьчеләр иленә әйләнеп бетәргә мөмкин. Мондый хәлдән безне Аллаһ үзе сакласын!

Шушы язмамны хәзерләгәндә, миңа берничә тапкыр Чаллы шәһәренең СПИД ка каршы көрәш һәм профилактика үзәгендә булырга туры килде. "Монда эшләүче кешеләргә Аллаһының рәхмәтләре булсын!" — дигән фикергә килдем. Алар бит көн саен, сәгать саен үлем чире белән очрашып, кеше кайгысын күреп, шушы афәтне булдырмас өчен җан-тәннәре белән көрәшә торган кешеләр! Үзәкнең башында үзебезнең милләт кешесе, зыялы ватанпәрвәр ГАЛИМҖАН әфәнде ЗАРИПОВның торуы да яхшы. Аның белән рәхәтләнеп, җаннарны ачып, сөйләшеп-киңәшеп була, дәүләт, милләт югарылыгында сүз йөртеп була. Гомумән, татар кешесе үзенә килгән бәла турында нәкъ татарча, үз милләттәшенә сөйләргә, ачылырга тиештер дип уйлыйм мин. Шуңа күрә наркоманиягә каршы татарча клублар, оешмалар да булырга тиеш дигән фикердә торам, чөнки урыс оешмаларындагы кайбер алымнар безнең өчен туры килми бит. Боларның барысын да Кама аръягында, Чаллыда Галимҗан әфәнде Зарипов, ул җитәкләгән үзәк каршында оештырырга, аның тирәсендә тупланырга кирәк, дип уйлыйм. Бу хәрәкәттә, язучы буларак, мин үзем дә катнашырга һәм ярдәм итәргә әзер.

— Мәкаләгездә чит илләрдә инде бик күптәннән кулланылган бушлай шприцлар һәм презервативлар таратуга каршы булуыгызны яшермисез. СПИД дигән, наркоманиядән дә хәтәррәк чир дә бар бит әле...

— Наркоманнарга бушлай шприцлар һәм презервативлар тарату — ул ялгыш юлга кереп китү, мин моны мәкаләмдә ныклап дәлилләдем, хәзер кабатлап тормыйм. Шуны гына өстәп әйтә алам: бушка шприцлар һәм презервативлвр таратып, сез нәтиҗә белән көрәшергә газашланасыз. Чөнки СПИД — ул инде коточкыч НӘТИҖӘ, иң соңгы этап, ә СПИДка, наркоманиягә кешене нинди СӘБӘПЛӘР китергән - монысы һаман читтә кала. Сез нәтиҗә белән көрәшергә чакырасыз, мин сәбәпне эзләп табып, аңа каршы көрәш башларга өндим. СПИД, НИГЕЗДӘ, АЗГЫНЛЫК СӘБӘПЛЕ КИЛЕП ЧЫККАН ЧИР — УЛ НАРКОМАННАР, ГОМОСЕКСУАЛИСТЛАР, ЗИНАЧЫЛАР АВЫРУЫ. Табибларның саксызлыгы яки мәкер юлы белән таратылу очраклары да бар, әмма алар гомумкүләмнән берничә процент кына. Димәк безгә, СПИДны булдырмау өчен, азгынлыкка, зинага, наркоманиягә, эчкечелеккә каршы ныклап, бөтен ил белән көрәшә башларга кирәк. Бөтен ил белән азып, эчеп ятарга түгел. Менә сез үз балагыз кулына шприц белән презерватив тоттырыр идегезме? Бу бит: “Зина кыл, әмма чирләмә генә!” — дигән сүз! Күңеле черек кешенең тәне дә черек була, ул иртәме-соңмы барыбер чирләячәк, авачак... Бәлки балаларыбыз кулына яшьтән үк шприц, презерватив түгел, ә изге догалар язылган китапларыбызны, милли әдәби мирасыбызны, мәгърифәт, хакыйкать нуры булырлык дәреслекләр тоттырырга кирәктер? Мин шулай уйлыйм...

— Адәм баласы ялгышмыйча тормый, аеруча яшьләр башка кешеләр яисә шайтан коткысына бирелүчән. Наркомания белән авыручыларның да күпчелеге яшьләр. Аларны бу афәттән ничек сакларга соң? Ана кеше буларак, Сез үз балаларыгызны ничек саклап кала алдыгыз?

— Минем балаларым, әлһәмдүлиллаһ, икесе дә дин юлында, һәм аларны мин түгел, Аллаһы Тәгалә саклый. Шуны

юлдан читкә тайпылган һәм үз нәфесенең колы булган кешене ата-ана да, гаилә, балалар да, мәхәббәт, эш-карьера да — берсе дә саклап кала алмаска мөмкин. Андый кешенең азгынлык өчен күңел ишекләре һәрвакыт ачык тора, кайчан нәрсә башлана — анысы бары тик вакыт эше. Күпчелек яшьләрнең наркоман булып китүе дә — үзләренең, ата-аналарының, җәмгыятьнең дөрес яшәмәве нәтиҗәсе. Кеше Аллаһны, аның тәртипләрен әйләнеп үтеп, бәхетле булырга теләде. Һәм менә - нәтиҗәсе. Әмма без кешеләргә барыбер ярдәм итәргә, хак юлга - Аллаһ юлына басарга чакырырга тиешбез. Үлгәнче, күзе йомылганчы кеше өчен көрәшергә, аны хакыйкатькә өндәргә, аның бәхетле буласына өметне өзмәскә кирәк. Мин бигрәк тә ата-аналарга сабырлык, акыл, миһербанлык, зур түземлекләр теләр идем. Үзебез дөрес яшәсәк, балаларыбыз да дөрес булыр. Хак юлга басуны һәркем үзеннән башларга тиеш.

— Наркоманиягә каршы каттый чаралар күрелә башлар дигән ышанычыгыз бармы?

— Беләсезме, наркомания проблемасы - ул без уйлаганга караганда да зуррак, житдирәк, куркынычрак проблема бит. Без хәзергә аның өстә яткан якларын гына күрәбез — наркоман яшьләр, наркомания аркасында килеп чыккан җинаятьләр, авырулар... Ә бит наркоманиянең бик тирәндә яткан кара тамырлары, катламнары бар —ул наркомафия, наркобизнес, наркодөнья... Ул —кеше бәхетсезлеге, кеше гомерләре хакына тупланган миллионлаган, миллиардлаган долларлар, хисапсыз байлык, шул байлыкны арттыру һәм саклау өчен тотылган җәза отрядлары... Кыскасы, хисапка бирелмәгән үз армиясе һәм капиталы булган, үз генераллары, үз корольләре, һәр илдә үз министрлары һәм депутатлары, сатлык матбугаты булган КҮЗГӘ КҮРЕНМӘГӘН БЕР КАРА, КАНЛЫ ДӘҮЛӘТ УЛ — НАРКОМАНИЯ ДӨНЬЯ-

сы... Аның белән күп илләр, шул исәптән, Америка, Европа илләре дә хисаплашырга, алар куйган таләпләрне кабул итәргә мәҗбүр. Хисаплашмыйсыз икән, наркомафия террор, үтерүләр белән җавап бирә. Алар эшне президентлар, дәүләт эшлеклеләре дәрәҗәсендә алып баралар, бөтен җирдә үз кешеләре, үрмәкүч авы кебек, агулы җәтмәләре... 11 сентябрь көнне Америкада эшләнгән терактның да артында наркомафия тора, дип уйларга нигез бар, чөнки Америка Колумбия наркомафиясенеең бик нык үкчәсенә баса башлаган иде. Һәм менә — канлы җавап...

Әлбәттә, бу кадәр зур, кара көчкә бөтен дөнья берләшеп кенә каршы тора ала. Ә дөнья, кызганычка каршы, мөселманнарга каршы берләшеп ята! Нинди зур ялгышу, нинди аяныч хәл! Наркомафия монда да үз теләгенә ирешеп килә — үзенә тиешле булган һөҗүмне мөселманнарга каршы борып җибәрде. Мөгаен, идеологик яктан ярдәм итүче, мөселманнар дошманы "Моссад" кебек оешмалар булгандыр... Әйе, наркмафиянең беренче дошманы - ислам дөньясы, чөнки мөселманнар үзләре наркотиклар кулланмыйлар, башкаларны да наркотикларга каршы көрәшергә өндиләр. Бөтен дөнья наркотиклардан баш тартса, ул чагында наркомафия ничек яшәр соң? Менә шуңа күрә алар барысы бергә берләшеп, мөселманнар өстенә ябырылдылар да инде...

Әгәр без, чыннан да, наркоманияне җиңәргә телибез икән, без ҮЗ НӘФЕСЕБЕЗНЕ һәм НАРКОМАФИЯНЕ җиңәргә тиеш булабыз. Нәфесне җиңү — идеологик һәм психологик фактор булса, наркомафияне җиңү, аның белән көрәш — ул инде каттый законнар һәм каты җәза алымнарын таләп итә. КҮҢЕЛНЕ ИМАН БЕЛӘН КОТКАРЫРГА КИРӘК, Ә НАРКОМАФИЯГӘ, НАРКОТИК МАТДӘЛӘР ТАРАТУЧЫЛАРГА КАРАТА КИСКЕН ЧАРАЛАР КҮРҮ ТИЕШЛЕ.

— Ислам динен, гомумән башка диннәрне дә көчәйтү наркоманиягә каршы көрәштә төп көч була аламы?

— Бөтен язмамда нәкъ шул хакта сөйләдем — бары тик АЛЛАҺ кушканча, ислам дине кысаларында яшәү, тормышка хәрәм кертмәү, иман ныклыгы дөрес нәтиҗәгә китерәчәк. Башка диннәр хакында шигем бар, бүгенге христиан дине,мәсәлән, эчкечелекне каттый тыймый бит, хәтта дини ритуаллары да аракы белән үтә. Ә кайда аракы — шунда хәрәм, шунда зина, бозыклык, наркоманиягә, СПИДка, җинаятьләргә туп-туры юл... Алла сакласын...

— Фәүзия ханым, бу темага әдәби әсәр язарга да теләгегез юкмы?

— Наркомания темасын өйрәнә башлаганда, бу хакта әдәби әсәр дә язып карарга кирәк, дигән уем бар иде... Әмма, мәсьәлә шул хәтле катлаулы һәм четркле ки, мин бераз туктап калдым... Әйе, әдәби әсәр язу өчен наркоман яшьләр прототиплары күп, алар, әнә, арабызда йөриләр. Әмма шушы яшьләрне агулап ятучы наркоторгашлар, һәр йортка, һәр подъездга ерак илләрдән наркотиклар ташучылар, аларны яшерен, “түбә” булып торучы хокук саклау органы хезмәткәрләре, кайбер намуссыз милиционерлар, республикада зур наркомафия башында торучы зур абзыйлар — әсәр өчен боларның барысын да белү, күрү кирәк бит. Минем яшьләр темасына гына багышланган бер күзәнәкле дежур, конъектур әсәр язасым килми. Ә зур, тирән, фаҗигале әсәр язу өчен әле материал тупларга кирәк. Кемдер бу өлкәдә миңа ярдәм итәргә, материал бирергә, тәҗрибә уртаклашырга тели икән, мин рәхмәт әйтеп, кабул итәчәкмен.

— “Өмет” газетасы редакциясенә һәм укучыларына нинди теләкләрегез бар?

— Гомумән, бу газетаның булуы үзе зур вакыйга. Чөнки бөтен татар дөньясында наркоманиягә каршы чыгучы

БЕРДӘНБЕР ТАТАРЧА ГАЗЕТА бит ул "ӨМЕТ"! Русларда исә мондый газеталар, мәгълүмат чаралары бик күп. "Өмет" газетасын бөтен Татарстанда таратырга, андагы кайбер язмаларны район газеталарында да бастырып чыгарырга иде! Безнең татар халкы, бигрәк тә — авылларда, наркомания, СПИД турында бернәрсә дә белмиләр бит! Мәгълүматлы булу — ул инде көрәшнең беренче адымы, ә берләшеп, киңәшеп, дөрес максат куеп эшләү — ул инде ярты җиңү, дигән сүз. Әйдәгез, бу ахыр заман афәтенә каршы бергәләп көрәш башлыйк, аның каршында куркып-каушап калмыйк, соңгы мизгелгә кадәр Аллаһ ярдәменнән өметне өзмик!

("Өмет" газетасы, 2001, N4)

Эчтәлек

Ахырзаман афәте 3

Наркомания — афәт ул 37

БАЙРАМОВА ФАУЗИЯ АУХАДИЕВНА

ТРАГЕДИЯ КОНЦА СВЕТА

Публицистика
(на татарском языке)
Учебно-методическое пособие

Китапны матбугат өчен әзерләүче
Җәмил САФИУЛЛИН

Корректоры Нажия ЗАКИРОВА
Техник редакторы Гөлшат ВӘЛИЕВА

"Аяз" нәшрияты. Нәшрият эшчәнлегенә 0207 нче номерлы лицензия 1997 елның 22 сентябрендә бирелгән.

Җыярга тапшырылды 01.12.01. Басарга кул куелды 20.12.01. Компьютерда җыелды. Офсет кәгазе. Офсет басма. Күләме 3,0 басма табак.

Заказ **Тираж 3000**

Оригинал-макет КУП "ЯР ЧАЛЛЫ" типографиясендә эшләнде, "Ислам нуры" дини-әшмәкәрлек Үзәге басмаханәсендә басылды. (Яр Чаллы шәһәре, Үзәк ур., 70)

ИСКӘРТМӘЛӘР ӨЧЕН